**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,
Дмитров урамы, 2
тел. 4-00-91
факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423962, с. Ютаза,
ул. Дмитрова, д.2
тел. 4-00-91
факс: 8 (85593) 4-00-93**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№8** **22.05.2024 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ санлы Федераль законның 13.4 маддәсе, 2018 елның 31 августындагы «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1039 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:
- №1 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын;
- 2 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрендәге «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында»гы 32 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет»

мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге **башлыгы** **Л.М.Хәйруллина**

2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары схемасы

Ютазы авылында





Фильтр
Найдено объектов 11432
Слои
Кама и К
Ютаза
ул. Загот. Зерно
р. Ютаза
© CNES 2013, Distribution Astrium Services/Spot Image, all rights reserved, © ООО ИТЦ «СКАНЭКС», Image © 2012 DigitalGlobe, Inc., © Яндекс Условия использования
Яндекс

Ютазы Кымыз белән дәвалау шифаханәсе бистәсендә



# Ык авылында


Фильтр
Найдено объектов 11432
Слои
Биек-Тау
ул. Мира
Ик
р. Ютаза
16К-0025
руч. Каркалинский
Каркале
Yandex
Image © 2012 DigitalGlobe, Inc., © ООО ИТЦ «СКАНЭКС», © CNES 2013, Distribution Astrium Services/Spot Image, all rights reserved, © Antrix Corporation Ltd., © Яндекс Условия использования
Яндекс

Алма-Ата авылында



Малиновка авылында



Керкәле авылында

